КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 3 сентябрь г.Казань № 778

2021/2022 уку елына Татарстан Республикасында ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгәннәр өчен һөнәри укытуның төп программаларын – эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең норматив чыгымнарын һәм күләмнәрен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2021/2022 уку елына Татарстан Республикасында ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгәннәр өчен һөнәри укытуның төп программаларын – эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең норматив чыгымнарын;

2021/2022 уку елына Татарстан Республикасында ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгәннәр өчен һөнәри укытуның төп программаларын – эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү күләмнәрен.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020/2021 уку елына Татарстан Республикасында ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгәннәр өчен һөнәри укытуның төп һөнәри белем бирү программаларын –

эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең норматив чыгымнарын һәм күләмнәрен раслау турында» 2019 ел, 6 сентябрь, 784 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Бу карар 2021 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 3 сентябрь, 778 нче
карары белән расланды

2021/2022 уку елына Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгәннәр өчен һөнәри укытуның төп программаларын – эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең норматив чыгымнары

| Әзерлек юнәлеше (белгечлек) коды | Әзерлек юнәлеше (белгечлек) исеме | Уку-укыту вакыты, ай | Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгән затларны һөнәри әзерләүгә норматив чыгымнар, бер кешегә сум | |
|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр җирлеге | авыл җирлеге |
| 13.01.10 | Электр җиһазларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча электромонтер (тармаклар буенча) | 5 | 9 694 | 10 882 |
| 43.01.09 | Пешекче, кондитер | 4 | 7 026 | 7 819 |
| 29.01.08 | Тегү җиһазлары операторы | 3 | 5 867 | 6 559 |
| 35.01.13 | Авыл хуҗалыгы җитештерүгә тракторчы-машинисты | 5 | 10 551 | 11 920 |

_______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 3 сентябрь, 778 нче
карары белән расланды

2021/2022 уку елына Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгәннәр өчен һөнәри укытуның төп программаларын – эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү күләмнәре

| Әзерлек юнәлеше (белгечлек) коды | Әзерлек юнәлеше (белгечлек) исеме | Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгән затларны һөнәри әзерләүгә дәүләт хезмәте күрсәтү күләме, кеше |
|---|---|---|
| «Мамадыш политехника көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе | | |
| 29.01.08 | Тегү җиһазлары операторы | 40 |
| 35.01.13 | Авыл хуҗалыгы җитештерүе тракторчы-машинисты | 20 |
| 13.01.10 | Электр җиһазларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча электромонтер (тармаклар буенча) | 20 |
| 43.01.09 | Пешекче, кондитер | 20 |

______________________________